**Уважаемые жители республики!**

Указом Президента Республики Татарстан от 25 сентября 2019 года № УП-572 в ознаменование 100-летия образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики, в целях широкого привлечения общественного внимания к важному историческому этапу становления и развития республики 2020 год в Республике Татарстан объявлен годом 100-летия образования Татарской АССР.

Столетие ТАССР – знаковая веха для Республики Татарстан и ее многонационального народа.

Согласно декрету Всероссийского Центрального Исполнительного комитета и Совета народных комиссаров РСФСР от 27 мая 1920 года образована Автономная Татарская Советская Социалистическая Республика (АТССР) *(25 июня 1937 года решением Чрезвычайного XI съезда Советов Татарской автономии порядок слов в названии республики был изменен, преобразовавшись в Татарскую Автономную Советскую Социалистическую Республику (ТАССР).*

30 августа 1990 года Верховный Совет ТАССР принимает Декларацию «О государственном суверенитете Республики Татарстан» и меняет название республики на «Татарскую Советскую Социалистическую Республику – Республику Татарстан».

С 7 февраля 1992 года республика носит название «Республика Татарстан».

21 апреля 1992 года Съезд народных депутатов РСФСР утверждает это название и вносит соответствующие изменения в Основной Закон РСФСР.

Старт празднованию 100-летия образования Татарской АССР будет дан 19 декабря 2019 года. На 2020-й год намечено более 1,5 тысячи событий федерального, республиканского, муниципального и городского уровней.

В плане подготовки к празднованию 100-летия образования Татарской АССР предусмотрено 75 основных мероприятий по четырем направлениям. Первое – это торжественные и праздничные события, включая крупные мероприятия: Игры стран Содружества Независимых Государств, Международный экономический саммит «Россия – Исламский мир: KazanSummit», Международный форум под эгидой ЮНЕСКО «Многообразие культур – фактор гуманитарной безопасности», форум породненных городов и муниципальных образований стран БРИКС и ряд других.

Второе направление посвящено культурно-просветительским и социально значимым учреждениям, а именно: гастролям татарских театров по стране, выставкам, творческим коллективам Татарстана. Третье - научные, издательские и информационные проекты. Четвертое направление касается строительства, ремонта и благоустройства.

Поскольку столетие - это не только региональный праздник, торжественные мероприятия пройдут в Москве, Санкт-Петербурге, других регионах и за рубежом.

Кроме того, в здании Международного выставочного центра «Казань Экспо» открыт концертный зал имени Ильгама Шакирова. Непосредственно в год юбилея в новое здание переедет Национальная библиотека Республики Татарстан, завершится ремонт здания бывшего Рабочего (Алафузовского) театра, где разместится театр «Созвездие-Йолдызлык».

*С более подробной информацией Вы можете ознакомиться на сайте http://100.tatarstan.ru/.*

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

**Хөрмәтле республика халкы!**

Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 25 сентябрендәге ПУ-572 номерлы Указы белән, Татарстан Республикасын торгызуның һәм үстерүнең мөһим тарихи этабына җәмәгатьчелек игътибарын киң җәлеп итү максатларында, 2020 ел Татарстан Республикасында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгы елы дип игълан ителде.

ТАССР йөзьеллыгы – Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы өчен әһәмиятле чор.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советы декреты нигезендә 1920 елның 27 маенда Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы (АТССР) оештырыла (1937 елның 25 июнендә Татар автономиясе Советларының Гадәттән тыш XI съезды карары белән, республика исемендәге сүзләр тәртибе, Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы (ТАССР) итеп үзгәртелә.

1990 елның 30 августында ТАССР Югары Советы «Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында» Декларация кабул итә һәм республиканың исемен «Татар Совет Социалистик Республикасы – Татарстан Республикасы» дип үзгәртә.

1992 елның 7 февраленнән республика «Татарстан Республикасы» исемен йөртә.

1992 елның 21 апрелендә РСФСР халык депутатлары съезды бу исемне раслый һәм РСФСР ның Төп Законына тиешле үзгәрешләр кертә.

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә 2019 елның 19 декабрендә Старт биреләчәк. 2020 елга федераль, республика, муниципаль һәм шәһәр дәрәҗәсендәге 1,5 меңнән артык вакыйга билгеләнгән.

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек планында дүрт юнәлеш буенча 75 төп чара каралган. Беренчесе – тантаналы һәм бәйрәм чаралары, шул исәптән зур чаралар: Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре уеннары, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисадый саммиты, ЮНЕСКО эгидасы астында «Мәдәниятләр күптөрлелеге – гуманитар иминлек факторы» Халыкара форумы, БРИКС илләренең токымлы шәһәрләре һәм муниципаль берәмлекләре форумы, һәм башкалар.

Икенче юнәлеш мәдәни-агарту һәм социаль әһәмияткә ия учреждениеләргә, аерым алганда, татар театрларының ил буйлап гастрольләренә, күргәзмәләргә, Татарстанның иҗат коллективларына багышланган. Өченчесе – фәнни, нәшрият һәм мәгълүмати проектлар. Дүртенче юнәлеш төзелеш, ремонт һәм төзекләндерүгә кагыла.

Йөзъеллык - ул төбәк бәйрәме генә түгел, тантаналы чаралар Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, башка төбәкләрдә һәм чит илләрдә узачак.

Моннан тыш, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге бинасында Илһам Шакиров исемендәге Концерт залы ачылды. Юбилей елында Татарстан Республикасының Милли китапханәсе яңа бинага күчәчәк, элеккеге Эшчеләр (Алафузов) театры бинасын ремонтлау эшләре тәгәлләнәчәк, анда «Созвездие-Йолдызлык» театры урнашачак.

*Тулырак мәгълүмат белән сез http://100.tatarstan.ru/ сайтында таныша аласыз.*

*Чыганак:* verhniy-uslon.tatarstan.ru сайты